**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «14» декабреннән № 39-318

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 91, 92 һәм 93 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (№2-9, 16.10.2015 ел; №9-32,11.02.2016 ел; №18-82, 28.09.2016 ел; №20-103, 14.12.2016 ел; №25-132, 17.04.2017 ел; №28-150 17.08.2017 ел; №31-180, 14.12.2017 ел; №37-209, 25.05.2018 ел; №43-252, 13.12.2018 ел; №50-299, 05.07.2019 ел; №61-378, 04.06.2020 ел; №10-70, 02.06.2021ел; №16-124, 09.12.2021ел; №24-181, 7.07.2022 ел; №32-245, 16.03.2023 ел карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 1 өлешендәге 31 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

1.2. 5) 6 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 41 пункт өстәргә:

«40) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерү.";

1.3. 6.1 статьяның 1 өлешендәге 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм

законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

1.4. Уставның 48 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктындагы җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

1.5. Уставның 49 статьясындагы 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Аерым оештыру-күрсәтмә функцияләрен гамәлгә ашыру өчен район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларга ия. Район Башкарма комитеты җитәкчесе җитди сәбәпләр аркасында вакытлыча булмаганда яки үз бурычларын үтәү мөмкинлеге булмаганда, вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, аның вәкаләтләрен район Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча) башкара»;

1.6. Уставның 68 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) затның, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, үзе дә як булып торган яклар конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чараларын кабул итмәве;»;

1.7. Уставның 68 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган белешмәләр йә, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру ;»;

1.8. Уставның 68 статьясындагы 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«2. Үзенә буйсынган затның мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасын, Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны биләүче зат, Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасын биләүче зат, Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазыйфасын биләүче зат, муниципаль вазыйфа кабул ителмәгән очракта, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, аңа буйсынган зат мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чаралары барлыкка килү турында билгеле булган Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасын биләүче таныган очракта, ышанычы югалуга бәйле рәвештә эштән азат ителергә тиеш.»;

1.9. Уставның 76 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«"Статья 76. Муниципаль хокукый актларның үз көченә керүе һәм халыкка җиткерелүе.

1. Муниципаль хокукый актлар, Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә торган салымнар һәм җыемнар турында район Советының норматив хокукый актларыннан тыш, район Уставында билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Кеше һәм граждан хокукларына, иреклəренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, муниципаль берәмлек гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

3. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрне, игълан итү тәртибе район Уставында билгеләнә һәм, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, гражданнар белән танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

4. Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне игълан итү дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) муниципаль хокукый актны рәсми бастырып чыгару;

2) чикләнмәгән затлар даирәсе өчен мөмкин булган урыннарда муниципаль хокукый актны урнаштыру (дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль китапханәләр биналарында, урыннарда йөрү өчен мөмкин булган башка урыннарда);

3) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыру;

4) район Уставында каралган башка ысул белән гражданнарны муниципаль хокукый акт, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешү белән таныштыру мөмкинлеген тәэмин итү.

5. Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне бастырып чыгару булып түбәндәгеләр санала:

- аның тулы текстының районда таратыла торган вакытлы матбугат басмасында «Яңа Чишмә хәбәрләре» газетасында беренче басмасы: www.novoshishminsk.ru;

- хокукый акт текстын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, урнаштыру;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы порталында: http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф урнаштыру»;

- хокукый акт текстын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру;

- хокукый акт текстын район торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру. Күрсәтелгән стендларның саны һәм аларның урнашу урыннары район Советы тарафыннан раслана һәм район халкы тарафыннан муниципаль хокукый акт тексты белән каршылыксыз танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Муниципаль хокукый акт текстын тулы күләмдә бастырып чыгаруның техник мөмкинлеге булмаган очракта, муниципаль хокукый акт текстының бер өлешен муниципаль хокукый акт тулысынча урнаштырылган ресурска сылтама күрсәтү шарты белән урнаштыру рөхсәт ителә.

Норматив-хокукый актлар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә бастырып чыгарылырга тиеш.

Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлектә гамәлгә ашырылса, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә аларны чикләнмәгән затлар даирәсе файдалана алырлык урыннарда (дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары биналарында, һәм урыннарга йөри алырлык дәүләт һәм муниципаль китапханәләрдә) аларны өстәмә техник чаралар кулланмыйча гына тоташтыруның бер яисә берничә пунктын булдыру тәэмин ителә.

7. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтның домен исемен һәм муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне рәсми бастырып чыгару гамәлгә ашырыла торган

массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында белешмәләрне күрсәтеп, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге вакытлы матбугат басмасы һәм (яисә) челтәр басмасы атамасы район Уставында күрсәтелә.

8. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның доменнарын һәм муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне, халыкка игълан итү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары буларак аларны теркәү турындагы белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге район Башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми игътибарга җиткерелә.».

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проекты турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының әлеге карар проектын кабул итәргә һәм гавами тыңлауларга чыгарырга.

4. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча 2023 елның 28 декабрендә сәг. 17.00 дә Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы,80 йорт адресы буенча урнашкан Яңа Чишмә муниципаль районы Советының актлар залында гавами тыңлаулар үткәрергә.

Гавами тыңлаулар тәртибе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-105 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://prvo.tatarstan.ru 2021 елның 30 сентябрендә бастырылган Яңа Чишмә муниципаль районының халык алдында тыңлаулар турындагы нигезләмәгә туры китереп гамәлгә ашырыла.

5. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә ачык тыңлаулар үткәрүне, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының күрсәтелгән карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә гавәми тыңлауларда яңгыраган һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы утырышына кертергә.

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгы

В. М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2023 елның «14» декабреннән
39-318 номерлы карарына
кушымта

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча: 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Совет урамы, 80 йорт, каб. № 314 язма рәвештә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге җитәкчесенә тапшырыла.

Тәкъдимнәр «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru халыкка җиткерелгән көннән алып эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр кабул ителә. http://novosheshminsk.tatarstan.ru

2. Ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 йорт, каб. № 314 шәхсән яки почта аша (конвертында«Устав турында фикер алышу» тамгасы белән).